Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
"Яна Кенәр балалар иҗаты Йорты" өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе

Программа педагогик
киңәшмәдә каралган
Беркетмә № 1
« 28 » август 2025 ел

"Раслыйм"
ӨБМБУ «ЯКБИЙ»директоры
_____________ Камалиева Г.М.
«01» 09 2025 ел

# Мәктәп театры «Сәләт»

Өстәмә гомумбелем программасы
сәнгать юнәлеше

Тормышка ашыру вакыты: 1 ел

Укучылар яше: 12-16 яшь

Автор-төзүче: Нигматуллина Л.С.
балаларга өстәмә белем бирү педагогы.

Яңа Кенәр, 2025 ел

## Укыту программасының мәгълүмати картасы

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы Арча районы "Яна Кенәр балалар иҗаты Йорты" өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе |
| 2 | Программаның тулы исеме | «Мәктәп театры«Сәләт» |
| 3 | Программаның юнәлеше | сәнгать |
| 4 | Автор-төзүче турында мәгълүмат | Автор-төзүче: Нигматуллина Л.С. балаларга өстәмә белем бирү педагогы. |
| 5<br><br>5.1. | Программа турында мәгълүмат<br><br>Үтәлү срогы | 1 ел |
| 5.2. | Укучыларның яше | 12-16 лет |
| 5.3. | Программага характеристика:<br>- программаның тибы<br>- программаның төре<br>-программаны проектлау принцибы<br>- укыту процессын карап тотуны һәм уку процессын оештыру формасы | Өстәмә гомумбелем программасы<br><br>гомумүсеш |
| 5.4. | Программаның максаты | сәләтле балаларны барлау, аларның иҗади сәләтен күрү һәм үстерү өчен җирлек әзерләү. |
| 6 | Белем бирү эшчәнлегенең формасы һәм алымнары | Практик эшләр, индивидуаль, төркемнәрдә эшләү,актерлык осталыгы буенча тренинглар, әңгәмә, уен, экскурсияләр. |
| 7 | Нәтиҗәлелек мониторингы формасы | Агымдагы: балаларны һәр дәрестә күзәтү.<br>Арадаш: бәйрәмнәр, ярышлар, зачётлар, конкурслар.<br>Йомгаклау: концертта катнашу, спектакль кую, ачык дәресләр. |
| 8 | Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге | Өйрәнгән спектакльләрне Яңа Кенәр балалар бакчасында, мәктәп укучылары каршында, ата-аналар җыелышларында, Яңа Кенәр интернат мәктәбендә, авыл Мәдәният йортында, китапханәдә үткәрелгән чараларда күрсәтү; район, районара, Республика кысаларында үткәрелгән конкурсларда катнашу. |
| 9 | Раслау һәм соңгы төзәтмәләр кертү датасы | |

**Эчтәлек**


1. Аңлатма язуы.........................................................................................4-5
2. Укыту планы.........................................................................................6-8
3. Программаның эчтәлеге..........................................................................9
4. Программа үтәлешендә көтелгән нәтиҗәләр...........................................10
5. Программаның материал яктан һәм техник тәэмин ителеше......................11
6. Аттестация һәм контроль эш формалары...............................................11
7. Бәяләү материалларының формасы.......................................................11
8. Кулланылган әдәбият..........................................................................12-13
9. Кушымта. Бәяләү материаллары..........................................................14-15
10. Календарь-укыту планы.....................................................................16-21

## Пояснительная записка

Сәнгать юнәлешендәге өстәмә гомумбелем программасы “Мәктәп театры “Сәләт” түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

1. “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы федераль закон (“Федеральный закон от 29.12.2012 № 273 – ФЗ . 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә кергән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)
2. Федераль законга укучыларны тәрбияләү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү хакында”гы федераль закон. (“Федеральный закон 0т 31 июля 2020 г. №304-ФЗ)
3. «Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәтләре күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында " 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль закон (28.12.2022 елдан үз көченә кергән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)
4. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 3.09.2019 №467 боерыгы белән расланган Балаларга өстәмә белем бирүнең төбәк системаларын үстерүнең максатчан моделе
5. РФ Хөкүмәтенең 2022 елның 31 мартындагы 678-р номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе
6. РФ Мәгариф министрлыгының «өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында " 2022 елның 27 июлендәге 629 номерлы боерыгы (2023 елның 1 мартыннан үз көченә керде һәм 2029 елның 28 февраленә кадәр гамәлдә)
7. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда электрон укытуны, дистанцион белем бирү технологияләрен куллану кагыйдәләрен раслау турында»11.10.2023 №1678 карары
8. «Белем бирү программаларын челтәр рәвешендә гамәлгә ашырганда белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру турында " Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 5 августындагы 882/391 номерлы боерыгы (2022 елның 26 июленә үзгәрешләр кертеп)
9. .Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 31.01.2022 №ДГ-245/06 хаты " электрон укытуны һәм дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча Методик тәкъдимнәр»
10. РФ Мәгариф министрлыгының «дәрестән тыш эшчәнлек курсларын, тәрбия һәм социализация программаларын, дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыру турында»2020 елның 7 маендагы вб-976/04 номерлы хаты
11. Россия Мәгариф министрлыгының 29.09.2023 ел, №АБ-3935/06 хаты «балаларга өстәмә белем бирү сыйфатын арттыруга юнәлдерелгән балаларның өстәмә белем бирү системасында эчтәлеген, методларын һәм технологияләрен яңарту механизмнарын формалаштыру буенча методик киңәшләр, шул исәптән эмоциональ, физик, интеллектуаль, рухи белемгә бәйле функциональ грамоталылык һәм компетентлык формалаштыруны тәэмин итүче компонентларны кертү Россия Федерациясенең гомуми белем бирү сыйфаты буенча дөньяның алдынгы ун иле исәбенә керүе өчен, илнең фәнни-технологик һәм мәдәни үсешенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру»
12. “Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының эчтәлегенә һәм эш режимын оештыруга санитар – эпидемиологик таләпләр” СанПин 2.4.3648-20 ( “Санитарно – эпидеомиологические требования организациям воспитания и обучения,отдыха и оздоровления детей и молодёжи" утверждены постановлением Главного санитарного врача Российской Федерации от 28.09.2020г.№28)
13. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «яңа редакциядә өстәмә гомуми белем бирү программаларын (шул исәптән җайлаштырылганнарын)

проектлау һәм гамәлгә ашыру буенча Методик тәкъдимнәр җибәрү турында»07.03.2023 ел, №2749/23 хаты

14. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кенәр балалар иҗаты йорты» уставы.

**Программаның актуальлеге.** Сәнгатьнең төрләре күп. Шулар арасында театр сәнгате аерым урын тота. Театр – ул искиткеч могҗиза. Могҗизаны бары хезмәт кенә тудыра. Хезмәткә мөнәсәбәт (бу очракта иҗади эш) кешенең рухи тормышында гаять әһәмиятле сыйфат. Бу уңайдан танылган педагог В.А. Сухомлинский болай дип язган: “Шатлык хисе көч куя, тир түгә һәм арыганлыкны тоя белгән кешегә хас. Балачак тоташ бәйрәм генә булырга тиеш түгел. Хезмәт киеренкелеге юк икән, бала өчен хезмәт бәхете дә юк. Шушы олы бәхеттән баланы мәхрүм итмәскә кирәк. Алар яшьтән үк хезмәтнең тәмен тоеп, үзләре эшләгән эшләрнең нәтиҗәсен күреп, горурланып үссеннәр”. Танылган педагогның әлеге киңәшләре түгәрәк эшчәнлегемне оештыруда нигез буларак кабул ителде.

Түгәрәктә сәхнә теле, сәнгатьлелек, иҗадилык, бәйләнешле сөйләм үстерү игътибар үзәгендә. Бердәмлек, дуслык һәм башка кеше тормышындагы әһәмиятле проблемаларга да урын бирелә. Татар халкының язучылары, шагыйрьләре, драматурглары, артистларын, аларның иҗатларын өйрәнү дә мөһим. Сәхнә сәнгатенең асылына төшенү өчен татар халык мәзәкләрен, өзекләрне, язучыларның әсәрләрен сәхнәләштерү, татар сәхнәсенә нигез салчы күренекле шәхесләребезнең иҗатларын өйрәнү, башкалабыздагы бөек театрларга экскурсияләр оештыру да карала.

Түгәрәктәге балаларның әти-әниләре белән элемтәдә тору өчен аларның чыгышларын карарга чакыру файдалы. Экскурсияләрне олылар белән бергәлектә оештыру мәктәп – гаилә – укучы чылбырының нык булуын күрсәтә.

Күренекле шәхесләрне өйрәнү, танылган кешеләр белән очрашулар аша туган телгә һәм халкыбызга мәхәббәт, ихтирам хисләре тәрбияләнә.

“Сәләтнең”нең эшчәнлеге милли традицияләрне халыкка җиткерүдә зур роль уйный, милли киемнәрнең кабатланмас бизәкләре халкымның үткәненә соклану хисләре тудыра, иң мөһиме: укучыларның сәләтләрен ачарга уй-хыялларын үстерергә мөмкинлек бирә, матурлыкны күрә белергә өйрәтә, иҗади эшчәнлекне баета.

**“Сәләт” түгәрәгенең максаты:**

сәләтле балаларны барлау, аларның иҗади сәләтен күрү һәм үстерү өчен җирлек әзерләү.

**Түгәрәк эшчәнлегенә куелган бурычлар:**

- укучыларда актер осталыгының, сәхнә сөйләменең бердәм комплексын булдыру;
- коллективта бергә килешеп эшләү;
- эстетик тәрбия бирү;
- хезмәтне ярату, бирелгән эшкә җаваплы карап, җиренә җиткереп үтәү.

**Программа адресаты** Программа 12-16 яшьлек укучылар өчен төзелә.

**Программа күләме**144 сәгать“Сәләт” түгәрәгендә өйрәнеләчәк материал 1 уку елына исәпләнә.

**Белем бирү процессын оештыру рәвешләре:** төркемнәрдә, индивидуаль, экскурсия

**Программаны үзләштерү вакыты:** 1 ел

**Программаның режимы:**шөгыльләр атнага 2 тапкыр, 2 шәр сәгать дәвамында үткәрелә.

## Укыту планы

| № | Бүлек . тема исеме | Сәгатьләр саны | | | Шөгыльләрне оештыру формасы | Аттестация (контроля) формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | теория | практика | | |
| **I** | **Кереш**. | **2** | **2** | | | |
| 1.1. | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру | 2 | 2 | | әңгәмә | |
| **II** | **“Театр яктылыкка, нурга илтә...” Сәхнә серләре.** | **22** | **16** | **8** | | |
| 2.1. | Театр сәнгате, аның төп үзенчәлеге.<br>Татар театры тарихы, анын беренче адымнары, үткән юлы.<br>Театрның үсеш баскычлары.<br>Беренче драматурглар, аларның әсәрләре | 8 | 4 | 2 | төркемнәрдә | зачет |
| 2.2. | Сәхнә серләренә өйрәнү. «Бичара кыз» әсәрен рольләргә бүлеп уку | 2 | 4 | 2 | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | агымдагы |
| 2.3. | Театрның беренче карлыгачлары.<br>Драма жанры төрләре. | 6 | 4 | 2 | әңгәмә | агымдагы |
| 2.4 | Сәхнә әсәрләрен иҗат итү, актерлык серләренә өйрәнү, өйрәтү дәресләре. Г.Камалның «Беренче театр» әсәреннән өзекләр карау<br>Кечкенә күләмле әсәрләр иҗат итү<br>Бүгенге драматурглар, аларнын ижат алымнары | 6 | 4 | 2 | укытучы сөйләве, әңгәмә | агымдагы |
| **III** | **Кәрим Тинчурин исемендәге Казан Татар дәүләт театрына виртуаль сәяхәт** | **16** | **14** | **2** | | |
| 3.1. | Театр тарихы белән танышу. | 2 | 2 | | практик | агымдагы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.2. | Кәрим Тинчурин исемендәге Казан Татар дәүләт театрында оештырыла торган махсус проектлар. | 2 | 2 | | практик | агымдагы |
| 3.3. | Театр буйлап экскурсия. (сайт буенча) | 2 | | 2 | практик | агымдагы |
| 3.4. | К.Тинчуринның "Сүнгән йолдызлар" спектаклен карау. | 2 | 2 | | практик | агымдагы |
| 3.5. | Татар театрының сәхнә осталары. Марсель Сәлимҗанов, Рауза Хәйретдинова, Ирек Баһманов**.** | 2 | 2 | | әңгәмә | агымдагы |
| 3.6. | Мизгел һәм гомер. Марсель Сәлимҗановның иҗат юлы. | 2 | 2 | | әңгәмә | агымдагы |
| 3.7. | Рауза Хәйретдинова. Гомер сәхнәсе. | 2 | 2 | | әңгәмә | агымдагы |
| 3.8. | Ирек Баһманов. Әлмәндәр улы. | 2 | 2 | | практик | агымдагы |
| **IV** | **Актер осталыгы.** | **88** | **30** | **58** | | |
| 4.1. | Актер осталыгы.Сәхнә теле. Сәнгатьле сөйләм. Рәсәйнең һәм Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗановның шигырь укуын аудиоязмада тыңлау. Х.Туфан шигырьләрен сәнгатьле уку. | 2 | 2 | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | агымдагы |
| 4.2. | Сәнгатьле уку. Батулла, Юныс Сафиуллин, Зөлфәт Хәким әсәрләрен сәнгатьле уку. | 6 | 6 | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | агымдагы |
| 4.3. | Шаян сүз, үткен тел. Аның роле нидә? К.Насыйриның "Иске мәдрәсәдә", "Аңгыралык бәласе" исемле мәзәкләрен сәнгатьле уку һәм сәхнәләштерү. | 10 | 10 | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | йомгаклау |
| 4.4. | Халык авыз иҗаты жанрлары белән танышу. | 2 | 2 | | әңгәмә | агымдагы |
| 4.5. | Әкият төрләре белән танышу, презентацияләү | 2 | 2 | | презентацияләү | агымдагы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.6. | Әкият иҗат итү. | 2 | | 2 | практик | агымдагы |
| 4.7. | Иҗат ителгән әкиятләрне сәхнәләштерү | 2 | | 2 | практик | агымдагы |
| 4.8. | Татар халык әкияте “Алтын алмалар” | 38 | | 38 | практик | агымдагы |
| 4.9. | Актер осталыгы. Г.Тукайга багышланган декада. | 10 | | | сәнгатьле уку | агымдагы |
| 4.10 | Сәхнәдә үзеңне тоту серләре. Г. Тукай әсәрләренең геройлары сәхнәдә (укучылар сайлый). | 2 | | 2 | практик | агымдагы |
| 4.11 | "Милли моңнар" шигырен сайлаучылар белән эш | 2 | | 2 | практик | агымдагы |
| 4.12 | "Милли моңнар" шигырен сайлаучылар белән эш | 6 | | | практик | агымдагы |
| 4.13 | “Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш" поэмасын сайлаучылар белән эш | 6 | 2 | 4 | практик | агымдагы |
| **V** | **Районыбыз талантлары.** | **12** | **8** | **10** | | |
| **5.1.** | ***Районыбыз талантлары.*** Районнан чыккан язучылар һәм сәнгать әһелләре белән танышу. | 2 | **2** | | әңгәмә | агымдагы |
| 5.2. | Районның “Әдәбият һәм сәнгать” музеена сәяхәт | 2 | | 2 | экскурсия | арадаш |
| 5.3. | Яңа Кырлай авылында урнашкан “Г.Тукай музеена” сәяхәт | 2 | | 2 | экскурсия | арадаш |
| 5.4. | Яңа Кенәр балалар иҗат йортының “Туган як”музеена сәяхәт | 2 | | 2 | экскурсия | арадаш |
| 5.5. | Мәктәп музеена сәяхәт | 2 | | 2 | экскурсия | арадаш |
| 5.6. | “Музейлардан алган тәэсирем” иҗади эш | 2 | | 2 | иҗади эш | зачет |
| **VI** | ***К. Тинчурин исемендәге татар Дәүләт Академия театрына сәяхәт.*** | **6** | **2** | **4** | | |
| 6.1 | К. Тинчурин исемендәге татар Дәүләт Академия театрына сәяхәт | 2 | | 2 | экскурсия | арадаш |
| 6.2 | “Театр дөньясы турында фикерләрем” иҗади эш. | 2 | | 2 | иҗади эш | зачет |
| 6.3. | Йомгаклау. | 2 | **2** | | әңгәмә | |
| | **Барлыгы** | **144** | **78** | **68** | | |

**Программаның эчтәлеге**

Темалар бүленеше түбәндәгечә бирелә:

***“Театр яктылыкка, нурга илтә...” Сәхнә серләре.* 22 сәг.**

*Кереш дәрес.* Куркынычсызлык кагыйдәләре белән танышу. Мониторинг (Кушымта № 1)

Түгәрәк эшчәнлегенең максаты, бурычлары белән таныштыру.

Татар театры тарихы, анынберенчеадымнары, үткән юлы.

Татар театрыныңбүгенгесе.

Драма жанры төрләре.

Әсәрне иҗат итәргә әзерләү, актерлык серләрен өйрәнү.

Хәрәкәтләр, мимика һәм гәүдә тотышы. Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле.

Видеоязмалар карау.

***Кәрим Тинчурин исемендәге Казан Татар дәүләт театрына виртуаль сәяхәт. 16 сәг.***

Театр тарихы белән танышу.

Театрда оештырыла торган махсус проектлар.

К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” спектаклен карау.

Театр буйлап экскурсия. (сайт буенча)

***Актер осталыгы. 88 сәг.***

Сәхнә теле. Сәнгатьле сөйләм. Рәсәйнең һәм Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗановның шигырь укуын аудиоязмада тыңлау.

Сәнгатьле уку. Батулла, Юныс Сафиуллин, Зөлфәт Хәким әсәрләрен сәнгатьле уку.

Т.Миңнуллинның «Кулъяулык» спектаклен карау.

Кечкенә кулэмле эсэрлэр (скетч, мэзэклэр) ижат иту

Шаян сүз, үткен тел. Аның роле нидә? К.Насыйри мәзәкләрен сәнгатьле уку һәм сәхнәләштерү.

***“Тукайны искә алып...”ны сәхнәләштерү.*** Халык авыз иҗаты жанрлары белән танышу.

***Актер осталыгы. Г.Тукайга багышланган декада.***

Сәхнәдә үзеңне тоту серләре. Г. Тукай әсәрләренең геройлары сәхнәдә.

***Районыбыз талантлары. 12 сәг.***

Районнан чыккан язучылар һәм сәнгать әһелләре белән танышу:

http://vafin.mugallim.com/( 20.09.2021)http://adiplar.belem.ru/banner.jpg ( 20.09.2021)

Районның “Әдәбият һәм сәнгать” музеена, Яңа Кырлай авылында урнашкан “Г.Тукай музеена”, Яңа Кенәр балалар иҗат йортының “Туган як”музеена, мәктәп музеена сәяхәт. Мониторинг. (Кушымта № 2)

***Кәрим Тинчурин исемендәге Казан Татар дәүләт театрына сәяхәт.* 6 сәг.**

Әти-әниләр белән бергә Г.Камал, К. Тинчурин исемендәге Дәүләт драма һәм комедия театрына сәяхәт.

***Йомгаклау.***

## Көтелгән нәтиҗәләр

Өйрәнгән спектакльләрне Яңа Кенәр балалар бакчасында, мәктәп укучылары каршында, ата-аналар җыелышларында, Яңа Кенәр интернат мәктәбендә, авыл Мәдәният йортында, китапханәдә үткәрелгән чараларда күрсәтү; район, районара, Республика кысаларында үткәрелгән конкурсларда катнашу.
Программа 12-16 яшьлек укучылар өчен тәкъдим ителә. Түгәрәктә дәресләр тематикасы куелган максатларны күз уңында тотып төзелә. Укучыларның иҗади эшчәнлеген оештыру һәм теория һәм практикага бәйләп алып барыла

## Аттестация һәм контроль эш формалары

**Шөгыльләрнең формасы:**
Практик дәрес, төркемнәрдә эшләү, актёрлык осталыгы буенча тренинглар, әңгәмә, уен-сәяхәт, экскурсия.

Балаларга сыйфатлы белем бирү максатыннан, шөгыльләр дистанцион укыту технологияләре һәм электрон ресурслар ярдәмендә дә үткәрелергә мөмкин (ZOOM, ватсап, һ.б.). Шөгыльләрне андый формада уздыру яңа буын укыту материалларын үз эченә алган цифрлы белем бирү ресурсларын җиңел кулланырга мөмкинлек бирәчәк.

**Контроль төрләре:**
Агымдагы: балаларны һәр дәрестә күзәтү.
Арадаш: бәйрәмнәр, ярышлар, зачётлар, конкурслар.
Йомгаклау: концертта катнашу, спектакль кую, ачык дәресләр.

## Программаны тормышка ашыруда оештыру шартлары

“Мәктәп театры “Сәләт” Арча районы С.З.Габдрахманова ис. Яңа Кенәр урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты кабинетында уздырыла. Программа үтәлеше һәм дәресләрне үткәрү өчен барлык уңайлыклар да тудырылган. Практик дәресләр мәктәпнең актлар залында уздырыла. Мәктәпнең материаль-техник базасы бар:

- Р.Тухфатуллин ис.татар теле һәм әдәбияты кабинеты -4 кабинет
- Парта һәм урындыклар
- Такта
- Проектор
- Компьютер
- Колонка
- Плакатлар, язучы-драматургларның портретлары
- Актлар залы

## Бәяләү материаллары

Аңлап уку күнекмәләре буенча биремнәр.

## Кулланылган әдәбият


1. Федеральный закон от 29.12.2012 №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» - статья 2 пункты 9, 10, 14; статья 10, пункт 7; статья 12 пункты 1, 2, 4; статья 23 пункты 3, 4; статья 28 пункт 2; статья 48 пункт 1; 75 пункты 1-5; 76

2. Концепция развития дополнительного образования детей (утверждена распоряжением Правительства Российской Федерации от 04.09.2014 №1726-р)

3. Көмеш тарак. Галимҗан Гыйльманов. Шигырьләр, пьесалар, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2000

4. Каюм Насыйри мәзәкләре.

5. «Методические рекомендации по проектированию дополнительных общеразвивающих программ (включая разноуровневые программы)» (направлены письмом Департамента государственной политики в сфере воспитания детей и молодёжи Министерства образования и науки Российской Федерации от 18.11.2015 № 09-3242)

6. «Об утверждении Общих требований к определению нормативных затрат на оказание государственных (муниципальных) услуг в сфере образования, науки и молодёжной политики, применяемых при расчёте объёма субсидии на финансовое обеспечение выполнения государственного (муниципального) задания на оказание государственных (муниципальных) услуг (выполнения работ) государственным (муниципальным) учреждением» (утверждены пунктом 4.1 приказа Министерства образования и науки Российской Федерации от 22.09.2015 №1040)

7. «О примерных требованиях к программам дополнительного образования детей» (Приложение к письму департамента молодёжной политики, воспитания и социальной поддержки детей МО и Н РФ от 11.12.2006 №06-1844)

8. План мероприятий на 2015-2020 годы по реализации Концепции развития дополнительного образования детей (утверждён распоряжением Правительства Российской Федерации от 24.04.2015 №729-р)

9. Порядок организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам (утверждён Приказом Министерства образования и науки России от 09.11.2018 №196)

10. Письмо Министерства образования и науки Российской Федерации от 14.12.2015 № 09-3564 «О внеурочной деятельности и реализации дополнительных общеобразовательных программ»

11. Приказ МОиН РТ № 1465/14 от 20 марта 2014 г. «Об утверждении Модельного стандарта качества муниципальной услуги по организации предоставления дополнительного образования детей в многопрофильных организациях дополнительного образования в новой реакции»

12. Приказ МОиН РТ № 2529/14 от 6 мая 2014 г. «Об утверждении Модельного стандарта качества муниципальной услуги по организации предоставления дополнительного образования детей в общеобразовательных организациях»

13. Положение об общеобразовательных общеразвивающих программах МБУ ДО «Дворец школьников» от 29.08.2016г.

14. СанПин 2.4.4.3.3172-14 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы образовательных организаций

дополнительного образования детей» (утверждены постановлением Главного санитарного врача Российской Федерации от 04.07.2014 №41)
15. Сабыйга. Габдулла Тукай.
16. Сайланма әсәрләр. Роберт Миңнуллин. Хәтер-2014
17. Татар әдәбиятыннан хрестоматия. 5 нче сыйныф өчен ярдәмлек, 1999
18. Татар классик драматургиясе. Тарих-2004
19. Татар пьесалары. Антология. Казан, Татарстан китапнәшрияты, 1987
20. «Экспертиза программ дополнительного образования детей, внеурочной деятельности и элективных курсов» (приложение к журналу «Внешкольник» - Бюллетень «Региональный опыт развития воспитания и дополнительного образования детей и молодёжи» № 4, 2014 г.)

**Кушымта 1**

## Бәяләү материаллары

1. **М.Әхмәтҗановның шигырен сәнгатле итеп укыгыз.**

Туган телгә өйрәттек.
Безнең авылга шәһәрдән
Кайтты бер кылтык малай.
Урысча гына сөйләшә,
Бер дә сер бирми алай.

Без дә төшеп калган түгел:
Урысчаны аңлыйбыз.
Тик “телеңне белмибез” дип
Шаяртабыз, алдыйбыз.

Җәй эчендә Айратыбыз
Урысчаны ташлады.
Безнең белән туган телдә
Сөйләшә дә башлады.

Кылтыклыгы да югалды,
Эрелеге дә бетте.
Шулай итеп, безнең авыл
Аны чын кеше итте.

**Аңлап уку күнекмәләре буенча биремнәр:**

1. Шигырьне игътибар белән укып чык, мәгънәви кисәкләргә бүлеп, исемнәр бир. (0-5 балл)
2. Укучылар, шигырь нәрсә турында иде? (Туган тел турында. Туган телнең кешене чын кеше итүе турында.) (0-5 балл)
3. ШӘҺӘРДӘН сүзендә басым кайсы иҗеккә төште? (соңгы иҗеккә төште. )
-Ә ни өчен соң ул соңгы иҗеккә төште? (Чөнки татар телендә басым соңгы иҗеккә төшә.) (0-5 балл)
4. АҢЛЫЙБЫЗ сүзендә басым кайсы иҗеккә төшә? (Басым 2 нче иҗеккә төшә.)
-Ә ни өчен икенче иҗеккә төшә? Нигә соңгы иҗеккә түгел? (Чөнки хәзерге заман хикәя фигыльләрдә басым зат- сан кушымчасы алдына төшә.) (0-5 балл)

**Белемнәрне бәяләү:**

19-20 – бик югары;

16-18- югары;

10-17- уртача;

0-9 – түбән

**“Ат чебене”**

**1.Текстны игътибар белән бер кат укып чык.**

Чын исеме Хәсән булса да, аны Калимәт малайлары “Ат чебене” дип йөртәләр иде. Ун яшеннән ул ат янында чуала башлады. Кәнүшнидә яңа бер колын туса, иң элек ул килеп җитә.

Унике яшеннән инде ул олы кешеләр ярдәменнән башка ат җигәргә өйрәнде. Атның ялына ябышып йөри, арба өстенә басып, камытын кидертә.Тик камыт бавын тартырга гына көче җитми аның. Эш шуңа килеп терәлгәч, борынын тартып, ат-арба тирәсендә әйләнә башлый...

Җәй көне Хәсән болында атлар янында. Чакырып алмасаң, ул ашарга да кайтмый.

Артышлытау буенда йомшак мүк үләне үсә. Үлән өстеннән мүкәләп бар-саң, күзне камаштырып, җир җиләге килеп чыга. Кып-кызыл!

Артыш арасында йөреп туйгач, Хәсән, әтисе кебек, кулларны баш астына куеп, йомшак мүк үләне өстенә сузылып ята. Рәхәт болай ятуы! Колак төбендә генә чикерткәләр сайраша, бал кортлары оча, үлән башларын сыйпап, җил исеп китә.

**2. Аңлап уку күнекмәләре буенча биремнәр:**

1. Кемне “Ат чебене” дип йөртәләр?

А) Хуҗа ә) Хәсән б) Хөсәен

2. Ничә яшьтән аңа “ат җене “ кагыла?

А) 12 ә) 10 б) 11

3. Артышлы тау өстендә йөреп арач, ул нәрсә өстендә ятарга ярата?

А)үлән ә) мүк үләне в) печән

4. Җәй көне ул кайларда йөри?

А) болында ә) су буенда в) кырда

5. Сер булмаса, үскәч, кем булырга телисең?

**Белемнәрне бәяләү:**

19-20 – бик югары;

16-18- югары;

10-17- уртача;

0-9 – түбән

**Кушымта 2**

# Календарь укыту графигы

| № | Название раздела, темы | Колич часов | Дата проведения | | Форма занятий | Форма контроля (аттеста-ции) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Всего | Число | Месяц | | |
| 1 | ***Кереш дәрес. “Театр яктылыкка, нурга илтә...” Сәхнә серләре.*** Куркынычсызлык кагыйдәләре белән танышу. | 2 | | | әңгәмә | агымдагы |
| 2 | Театр сәнгате, аның төп үзенчәлеге. | 2 | | | әңгәмә | агымдагы |
| 3 | Татар театры тарихы, анын беренче адымнары, үткән юлы. | 2 | | | әңгәмә | агымдагы |
| 4 | Театрның үсеш баскычлары, формалашу чоры | 2 | | | практик | агымдагы |
| 5 | Беренчедраматурглар, аларныңәсәрләре | 2 | | | төркемнәрдә эш | агымдагы |
| 6 | ***Сәхнә серләренә өйрәнү.*** «Бичара кыз» әсәрен рольләргә бүлеп уку | 2 | | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | агымдагы |
| 7 | ***Театрныңберенче карлыгачлары:*** Габдулла Кариев, С.Волжская һ.б. турында истәлекләр. Беренче труппалар, ачык театр көне турында белешмә. | 2 | | | әңгәмә | агымдагы |
| 8 | ***Драма жанры төрләре:*** трагедия, комедия, драма, водевил, мелодрама | 2 | | | укытучы сөйләве, әңгәмә | агымдагы |
| 9 | ***Сәхнә әсәрләрен иҗат итү, актерлык серләренә өйрәнү, өйрәтү дәресләре***. Г.Камалнның «Беренче театр» әсәреннән өзекләр карау | 2 | | | практик | агымдагы |
| 10 | Кечкенә күләмле әсәрләр (скетч, мәзәкләр) иҗат итү | 2 | | | практик | агымдагы |
| 11 | Бүгенге драматурглар, аларнын иҗат алымнары: Г.Камал театры коллективы эшчәнлеге; К.Тинчурин исемендәге театр артистлары, аларның иҗаты, театр сәнгатендә тоткан урыннары. | 2 | | | практик | агымдагы |
| 12 | ***Кәрим Тинчурин исемендәге Казан Татар дәүләт театрына виртуаль сәяхәт.*** Театр тарихы белән танышу. https://tinchurinteatr.ru/ | 2 | | | практик | агымдагы |
| 13 | Кәрим Тинчурин исемендәге Казан | 2 | | | практик | спектакль |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татар дәүләт театрында оештырыла торган махсус проектлар. https://tinchurinteatr.ru/2 | | | | | кую |
| 14 | Театр буйлап экскурсия. (сайт буенча) https://tinchurinteatr.ru/ | 2 | | | практик | спектакль кую |
| 15 | К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” спектаклен карау. https://tinchurinteatr.ru/ | 2 | | | практик | спектакль кую |
| 16 | ***Татар театрының сәхнәосталары. Марсель Сәлимҗанов, Рауза Хәйретдинова, Ирек Баһманов.*** | 2 | | | әңгәмә | агымдагы |
| 17 | Мизгел һәм гомер. Марсель Сәлимҗановның иҗат юлы. | 2 | | | әңгәмә | агымдагы |
| 18 | Рауза Хәйретдинова. Гомер сәхнәсе. | 2 | | | әңгәмә | агымдагы |
| 19 | Ирек Баһманов. Әлмәндәр улы. | 2 | | | практик | агымдагы |
| 20 | ***Актер осталыгы.*** Сәхнә теле. Сәнгатьле сөйләм. Рәсәйнең һәм Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗановның шигырь укуын аудиоязмада тыңлау. Х.Туфан шигырьләрен сәнгатьле уку. | 2 | | | Сәнгатьле уку | агымдагы |
| 21 | ***Сәнгатьле уку. Батулла, Юныс Сафиуллин, Зөлфәт Хәким әсәрләрен сәнгатьле уку.*** Сәнгатьле уку – үрнәк уку, тамашычының күңеленә барып житү һәм хис уяту өчен текст белән ничек эшләргә икәнлеген аңлату. | 2 | | | Сәнгатьле уку | агымдагы |
| 22 | Шигырьне уку; сүз һәм сүзтезмә, сүз басымын билгеләү; логик басымны билгеләү; мәгьнәви кисәкләргә бүлү. | 2 | | | Сәнгатьле уку | агымдагы |
| 23 | Тыныш билгеләренә игьтибар итү; озын пауза, кыска паузаны билгеләү; тавыш күтәрелеше һәм төшүен билгеләү; интонация. | 2 | | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | агымдагы |
| 24 | ***Шаян сүз, үткен тел. Аның роле нидә? К.Насыйриның "Иске мәдрәсәдә", "Аңгыралык бәласе" исемле мәзәкләрен сәнгатьле уку һәм сәхнәләштерү.*** Сәхнә теле, сәхнәдә үзен табигый тоту кагыйдәләре, текстны сәнгатьле итеп | 2 | | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | агымдагы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | ятлау, шаян телнең тәэсир көче, юмор һәм сатира турында мәгълүмат бирү. | | | | | |
| 25 | К.Насыйриның "Иске мәдрәсәдә", "Аңгыралык бәласе" исемле мәзәкләрен уку;эчтәлеген аңлау; үткен тел, юмор, аның роле; сүз басымы, тыныш билгеләренәигътибар итү; пауза, интонация, тавыш куелышы. | 2 | | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | агымдагы |
| 26 | Сәхнәләштерү өстендә эшләү: рольләр бүлеп бирү; актерның үз өстендә эшчәнлеге. | 2 | | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | агымдагы |
| 27 | Сәхнәләштерү өстендә эшләү: рольләр бүлеп бирү; актерның үз өстендә эшчәнлеге. | 2 | | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | агымдагы |
| 28 | Бәяләү. К. Насыйри хикәятләрендә шул чор җитешсезлекләрен үткен тел белән тәнкыйтьләү осталыгын билгеләү. | 2 | | | актёрлык осталыгы буенча тренинглар | йомгаклау |
| 29 | ***“Тукайны искә алып...”ны сәхнәләштерү.***Халык авыз иҗаты жанрлары белән танышу. | 2 | | | әңгәмә | агымдагы |
| 30 | Әкият төрләре белән танышу, презентацияләү | 2 | | | презентациял әү | агымдагы |
| 31 | Әкият иҗат итү. | 2 | | | практик | агымдагы |
| 32 | Иҗат ителгән әкиятләрне сәхнәләштерү | 2 | | | практик | агымдагы |
| 33 | ***“Тукайны искә алып...”***, 1 нче күренеш | 2 | | | практик | агымдагы |
| 34 | Рольләр буенча сәнгатьле уку, 1 нче күренеш | 2 | | | практик | агымдагы |
| 35 | “Тукайны искә алып...” буенча рольләр бүлешү | 2 | | | практик | агымдагы |
| 36 | Рольләрне башкаручыларны аерым-аерым тыңлау. Апуш ролен башкаручы артист белән эш. | 2 | | | практик | агымдагы |
| 37 | Абый ролен башкаручы артист белән эш. | 2 | | | практик | агымдагы |
| 38 | Шүрәле ролен башкаручы артист белән эш. | 2 | | | практик | агымдагы |
| 39 | Былтыр ролен башкаручы артист белән эш. | 2 | | | практик | агымдагы |
| 40 | Су анасыролен башкаручы артистлар белән эш | 2 | | | практик | агымдагы |
| 41 | Кәҗә ролен башкаручы артистлар белән эш | 2 | | | практик | агымдагы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 42 | Сарык ролен башкаручы артистлар белән эш, | 2 | | | практик | агымдагы |
| 43 | Рольләрне башкаручы артистлар белән күмәк эш. | 2 | | | практик | агымдагы |
| 44 | Әкият-тамашаны башкаручылар белән бердәм эш, хәрәкәтләр кую | 2 | | | практик | агымдагы |
| 45 | Әкият-тамашаны башкаручылар белән бердәм эш, хәрәкәтләр кую | 2 | | | практик | агымдагы |
| 46 | Әкият-тамашаны башкаручылар белән бердәм эш, хәрәкәтләр кую | 2 | | | практик | агымдагы |
| 47 | Сәхнәдә чыгыш ясарга өйрәнү: сәхнәдә үзләрен табигый тоту; дөрес, аһәңле сөйләм теле булдыру; хәрәкәтләнү күнегүләре | 2 | | | практик | агымдагы |
| 48 | Сәхнәдә чыгыш ясарга өйрәнү: сәхнәдә үзләрен табигый тоту; дөрес, аһәңле сөйләм теле булдыру; хәрәкәтләнү күнегүләре | 2 | | | практик | агымдагы |
| 49 | Сәхнәдә чыгыш ясарга өйрәнү: сәхнәдә үзләрен табигый тоту; дөрес, аһәңле сөйләм теле булдыру; хәрәкәтләнү күнегүләре | 2 | | | практик | агымдагы |
| 50 | Сәхнәдә чыгыш ясау | 2 | | | практик | йомгаклау |
| 51 | Фикер алышу, бәяләү. | 2 | | | әңгәмә | йомгаклау |
| 52 | ***Актер осталыгы. Г.Тукайга багышланган декада.(140 еллыгы уңаеннан) үткәрелгән чараларга катнашу)*** Осталыкка сәхнә өчен иң кирәкле сыйфатлар: сәнгатьле сөйләм, йөз, хәрәкәт, сәхнәдә үз-үзеңне тоту. Ирешүнең юлы – үз өстеңдә туктаусыз эшләү. | 2 | | | практик | агымдагы |
| 53 | Г.Тукайга багышланган декадада катнашу өчен төркемнәрдә эш: әсәр сайлау, сәнгатьле уку, сәхнәләштерү | 2 | | | сәнгатьле уку | агымдагы |
| 54 | Текст өстендә эш: эчтәлеген аңлау; сүзләргә басым; логик басым; мәгънәви кисәкләргә бүлү; тыныш билгеләре; озын һәм кыска пауза; тавыш куелышы; тавыш үзгәреше (төшүе, менүе), сәнгатьле уку. | 2 | | | сәнгатьле уку | агымдагы |
| 55 | Сәхнәдә чыгыш ясау. | 2 | | | практик | йомгаклау |
| 56 | Фикер алышу, бәяләү. | 2 | | | әңгәмә | йомгаклау |
| 57 | ***Сәхнәдә үзеңне тоту серләре. Г. Тукай әсәрләренең геройлары сәхнәдә (укучылар сайлый).*** Сәхнәдә үзеңне иркен, табигый тоту, тормыш материалын үзеңнең | 2 | | | практик | агымдагы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | байфантазияң белән тулыландыру әһәмиятле турында мәгълүмат бирү. Кызыксынучанлык, игътибарлылык, яхшы хәтер булдыру өстендә эшләү серләре. | | | | | |
| 58 | ***"Милли моңнар" шигырен сайлаучылар белән эш:*** сәнгатьле уку; сүзләргә басым; логик басым; мәгънәви кисәкләргә бүлү; тыныш билгеләренә игътибар; озын, кыска пауза; интонация; тавыш күтәрелеше, төшүе; үрнәктәгечә уку | 2 | | | практик | агымдагы |
| 59 | Сәнгатьле уку; сүзләргә басым; логик басым; мәгънәви кисәкләргә бүлү; тыныш билгеләренә игътибар; озын, кыска пауза; интонация; тавыш күтәрелеше, төшүе; үрнәктәгечә уку | 2 | | | практик | агымдагы |
| 60 | Сәнгатьле уку; сүзләргә басым; логик басым; мәгънәви кисәкләргә бүлү; тыныш билгеләренә игътибар; озын, кыска пауза; интонация; тавыш күтәрелеше, төшүе; үрнәктәгечә уку | 2 | | | практик | агымдагы |
| 61 | ***“Ана догасы", “Шагыйрь”шигырьләресайлаучылар белән эш*** | 2 | | | практик | агымдагы |
| 62 | Сәнгатьле уку; сүзләргә басым; логик басым; мәгънәви кисәкләргә бүлү; тыныш билгеләренә игътибар; озын, кыска пауза; интонация; тавыш күтәрелеше, төшүе; үрнәктәгечә уку | 2 | | | практик | агымдагы |
| 63 | Сәнгатьле уку; сүзләргә басым; логик басым; мәгънәви кисәкләргә бүлү; тыныш билгеләренә игътибар; озын, кыска пауза; интонация; тавыш күтәрелеше, төшүе; үрнәктәгечә уку | 2 | | | практик | агымдагы |
| 64 | ***Районыбыз талантлары.*** Районнан чыккан язучылар һәм сәнгать әһелләре белән танышу. | 2 | | | әңгәмә | агымдагы |
| 65 | Районның “Әдәбият һәм сәнгать” музеена сәяхәт | 2 | | | экскурсия | арадаш |
| 66 | Яңа Кырлай авылында урнашкан “Г.Тукай музеена” сәяхәт | 2 | | | экскурсия | арадаш |
| 67 | Яңа Кенәр балалар иҗат йортының “Туган як”музеена сәяхәт | 2 | | | экскурсия | арадаш |
| 68 | Мәктәп музеена сәяхәт | 2 | | | экскурсия | арадаш |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 69 | “Музейлардан алган тәэсирем” иҗади эш | 2 | | | иҗади эш | зачет |
| 70 | ***К. Тинчурин исемендәге татар Дәүләт Академия театрына сәяхәт.*** | 2 | | | экскурсия | арадаш |
| 71 | “Театр дөньясы турында фикерләрем” иҗади эш | 2 | | | иҗади эш | зачет |
| 72 | ***Йомгаклау*** | 2 | | | әңгәмә | йомгаклау |